| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 539-23/э-2020

Татарстан Республикасында халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләштерелгән категорияләренә 2021 елга электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) киметүле коэффициентлар куллану хакында

"Электр энергетикасы турында" 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр энергетикасы өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында" 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр авыл торак пунктларында яшәүчеләр өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата 0,7 киметү коэффициенты кулланыла дип билгеләргә.

2. 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап 2021 елның 30 июненә кадәр шәһәр торак пунктларында билгеләнгән тәртиптә азык әзерләү өчен стационар электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыта торган җайланмалар белән тәэмин ителгән йортларда яшәүче халык өчен электр энергиясенә булган бәяләргә (тарифларга) 0,7 киметү коэффициенты кулланыла дип билгеләргә.

3. 2021 елның 1 июленнән башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр шәһәр торак пунктларында билгеләнгән тәртиптә азык әзерләү өчен стационар электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыта торган җайланмалар белән тәэмин ителгән йортларда яшәүче халык өчен электр энергиясенә булган бәяләргә (тарифларга) 0,7183 киметү коэффициенты кулланыла дип билгеләргә.

4. 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән аерым категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметү коэффициентлары әлеге карар кушымтасына туры китереп кулланыла, дип билгеләргә.

5. 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр, шушы карарның 4 пунктында күрсәтелгән кулланучылардан тыш, Татарстан Республикасында халыкка тиңләштерелгән кулланучылар өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметү коэффициенты кулланылмый, дип билгеләргә.

6. Бу карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 539-23/э-2020
карарына кушымта

## Татарстан Республикасында кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән категорияләре өчен 2021 елга электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) киметүле коэффициентлар

| № т/с | Кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән категорияләре | Киметүле коэффициентлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I яртыеллык | | II яртыеллык | |
| | | шәһәр торак пунктларында урнашкан, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган торакларда торучылар | Авыл торак пунктларында булган | шәһәр торак пунктларында урнашкан, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган торакларда торучылар | Авыл торак пунктларында булган |
| 1 | Коммерциясез бакчачылык ширкәтләре һәм коммерциясез яшелчәчелек ширкәтләре.<br>Электр энергиясен (егәрлеген) алга таба халыкка һәм аңа тиңләштерелгән, кулланучыларның әлеге пунктта күрсәтелгән категорияләренә сату максатларында сатып алучы гарантияле тщэминатчылар, энергия сатучы, энрегия белән тәэмин итүче оешмалар. <1> | 0,7 | 0,7 | 0,7183 | 0,7 |
| 2 | Мәхәллә кешеләре хисабына яшәүче дини оешмалар. | - | 0,7 | - | 0,7 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Электр энергиясен (егәрлеген) алга таба халыкка һәм аңа тиңләштерелгән, кулланучыларның әлеге пунктта күрсәтелгән категорияләренә сату максатларында сатып алучы гарантияле тщэминатчылар, энергия сатучы, энрегия белән тәэмин итүче оешмалар. <1> | | | | |

<1> Электр энергиясен (егәрлеген) алга таба халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләштерелгән категорияләренә караган тиешле кулланучы категорияләре булган очракта, халык һәм аңа тиңләштерелгән кулланучы категорияләре тарафыннан фактта куллану күләмнәрендә һәм гражданнарның коммуналь-көнкүреш ихтыяҗларында файдалану максатларында уртак файдаланыла торган урыннарга тотылган һәм коммерцияле (һөнәри) эшчәнлек башкару өчен кулланылмый торган электр энергиясе күләмнәрендә сату максатларында сатып алучы гарантияле тәэминатчылар, энергия сатучы, энергия белән тәэмин итүче оешмалар.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге